ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.05.2024 г. Казань № 328/2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларын үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.05.2024 ел, №10-ПР беркетмәсе нигезендә, норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип таныргa:

«Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибен раслау турында» 04.03.2020 № 32;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 4 мартындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 23.06.2021 № ПР-430/2021.

2. Бу боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев